КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 20 февраль 112

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 22 декабрь, 912 нче, 2010 ел, 19 июль, 577 нче, 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче, 2012 ел, 7 февраль, 88 нче, 2012 ел, 12 октябрь, 847 нче, 2013 ел, 21 март, 196 нчы, 2013 ел, 11 июнь, 399 нчы, 2013 ел, 28 июнь, 446 нчы, 2013 ел, 29 август, 612 нче, 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче, 2014 ел, 1 март, 133 нче, 2014 ел, 18 апрель, 255 нче, 2014 ел, 8 октябрь, 742 нче, 2015 ел, 22 гыйнвар, 28 нче, 2015 ел, 9 февраль, 72 нче, 2015 ел, 6 июль, 490 нчы, 2016 ел, 30 апрель, 269 нчы, 2016 ел, 9 июнь, 382 нче, 2016 ел, 12 октябрь, 737 нче, 2016 ел, 23 декабрь, 977 нче, 2017 ел, 6 март, 130 нчы, 2017 ел, 26 июнь, 439 нчы, 2017 ел, 7 декабрь, 950 нче, 2018 ел, 14 март, 151 нче, 2018 ел, 11 июнь, 461 нче, 2018 ел, 15 декабрь, 1139 нчы, 2019 ел, 15 июнь, 493 нче, 2019 ел, 2 июль, 525 нче, 2019 ел, 30 август, 735 нче, 2019 ел, 20 сентябрь, 859 нчы, 2020 ел, 28 гыйнвар, 31 нче, 2020 ел, 25 февраль, 141 нче, 2020 ел, 15 сентябрь, 830 нчы, 2020 ел, 10 ноябрь, 1006 нчы, 2021 ел, 26 апрель, 284 нче, 2021 ел, 15 июнь, 455 нче, 2021 ел, 19 июль, 587 нче, 2022 ел, 22 февраль, 153 нче, 2022 ел, 21 апрель, 380 нче, 2022 ел, 4 июль, 624 нче, 2022 ел, 21 октябрь, 1128 нче, 2022 ел, 18 ноябрь, 1236 нчы, 2022 ел, 26 декабрь, 1418 нче, 2023 ел, 19 апрель, 498 нче, 2023 ел, 26 июль, 887 нче, 2024 ел, 20 март, 169 нчы, 2024 ел, 13 июнь, 423 нче, 2024 ел, 23 ноябрь,

1046 нчы, 2025 ел, 17 апрель, 236 нчы, 2025 ел, 7 май, 301 нче, 2025 ел, 9 декабрь, 1065 нче, 2025 ел, 29 декабрь, 1183 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктның 3.3.261 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.26$^{1}$. Татарстан Республикасы милкендәге җирләргә яисә җир кишәрлекләренә карата, шулай ук авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләренә карата, федераль милектәге җирләрдән тыш, җирләрне яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерү турындагы үтенечнамәләрне карый.

Законда билгеләнгән очракларда үтенечнамәләрне карамыйча кире кайтаруны гамәлгә ашыра.

Түбәндәгеләрне әзерли һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы милкендәге җирләргә яисә җир кишәрлекләренә карата, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш, мондый җирләрне бер категориядән икенчесенә күчерү турында карарлары проектлары;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен, федераль милектәге җирләрдән тыш, башка категориягә күчерүне күздә тоткан Татарстан Республикасы законнары проектлары.

Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләренә карата, федераль милектәге җирләрдән тыш, җирләрне яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән башка категориягә күчерү йә мондый күчерүдән баш тарту турында законнар нигезендә күрсәтмәләр чыгара.»;

4.3 пунктның 4.3.5 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләренә карата Министрлык җирләрне яисә мондый җирләр составында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында боерыклар кабул иткән очракта җирләрнең категориясе һәм рөхсәт ителгән файдалану төре өлешендә җирләр яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләре турындагы белешмәләрне үзгәртү турында мәгълүматлы үз эченә алган формалаштырылган документларның архивы – xml-форматта һәм күрсәтелгән карарларның pdf-форматындагы күчермәләре.».

2. Бу карар 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин